КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1282

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 март, 175 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2017 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1542 нче карары нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1640 нчы карары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның икенче абзацында «2017 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2017 елга Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 декабрь, 1089 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 декабрь, 1282 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында
Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте
база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме
күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүне (алга таба – югары технологияле медицина ярдәме) финанслар белән тәэмин итү Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджетыннан түбәндәгеләр рәвешендә бирелә:

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә план йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – Фонд, бюджетара трансфертлар);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары хезмәткәрләренең эш хакын арттыру чараларын финанслар белән тәэмин итүгә, шул исәптән Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын үтәү кысаларында.

4. Бюджетара трансфертларны тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша Фонд тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан акчаларны тоту Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

6. Югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүне финанслар белән тәэмин итүгә Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме, югары технологияле медицина ярдәменең тиешле профиле төрләре (ысуллары) буенча югары технологияле медицина ярдәме күрсәтеләчәк Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче гражданнарның планлаштырылган санынннан һәм югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә медицина ярдәме күрсәтү күләме берәмлегенә финанс чыгымнары нормативларыннан чыгып, Татарстан Республикасы медицина оешмалары яктылыгында билгеләнә.

Югары технологияле медицина ярдәменең тиешле профиле төрләре (методлары) буенча югары технологияле медицина ярдәме күрсәтеләчәк Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәүче гражданнарның планлаштырылган саны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турындагы килешүдә (алга таба – Килешү) билгеләнә.

Югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә медицина ярдәме күрсәтү күләме берәмлегенә финанс чыгымнары нормативлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелә торган мәҗбүри медицина иминияте системасы аша Татарстан Республикасы медицина оешмаларын башлыча бер каналлы финанслауны тормышка ашыруга Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәме өчен түләү тәртибен һәм тарифларны билгеләү турындагы тариф килешүе белән раслана.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелә торган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары хезмәткәрләренең эш хакын арттыру параметрларыннан һәм дәүләт медицина оешмаларының хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләү буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарында каралган акчалар күләменнән чыгып билгеләнә.

8. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы агымдагы айның 20сенә кадәр Фондның бюджет заявкалары нигезендә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгән финанслауның чик күләмнәре чикләрендә бюджетара трансфертларны Фонд бюджетына бирә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы бюджет һәм автоном булып торган учреждениеләр белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүнең типовой формасын раслау турында " 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзи;

медицина оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирә.

10. Фонд:

законнар нигезендә исемлеге Килешүдә билгеләнгән Татарстан Республикасы медицина оешмалары белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бертип форма буенча югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү турында шартнамәләр төзи;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ай саен, агымдагы айның 15еннән дә соңга калмыйча, бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет заявкасын тапшыра;

медицина оешмаларына түбәндәге шартлар үтәлгәндә күчерә:

медицина оешмалары Фонд күчергән акчадан мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен файдаланса;

медицина оешмалары югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле медицина хезмәтләренең һәм чыгымнарның, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелгән гражданнарның аерым исәбен алып барса;

медицина оешмалары хисап аеннан соң килә торган айның биш эш көненнән дә соңга калмыйча Фондка счетлар реестрын һәм күрсәтелгән югары технологияле медицина ярдәме өчен түләүгә счет кертсә. Агымдагы финанс елының декабре өчен счетлар реестры һәм күрсәтелгән югары технологияле медицина ярдәме өчен түләүгә счет Фондка агымдагы елның 22 декабреннән соңга калмыйча кертелә.

11. Татарстан Республикасы медицина оешмаларына аванс бирү Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар кергән көннән алып биш көн эчендә билгеләнгән план йөкләмәсенең уртача айлык күләменнән иң күбе 50 процент күләмендә Фонд тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Фонд Татарстан Республикасы медицина оешмалары керткән счетлар реестрларына билгеләнгән тәртиптә медицина-икътисадый экспертиза үткәрә һәм ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 20сеннән дә соңга калмыйча, түләнгән авансны исәпкә алып, аларга түләүне гамәлгә ашыра. Хисап елының декабре өчен счетлар реестры өчен түләү Фонд тарафыннан хисап елының 26 декабреннән соңга калмыйча башкарыла. Акча күчерү Фондның Россия Федерациясе гражданнарына югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны

финанслар белән тәэмин итүе турындагы шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

12. Медицина оешмалары югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен алган акчаны югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүдә катнаша торган медицина хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә, хезмәт өчен түләүгә, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен дару чаралары һәм тотыла торган материаллар сатып алуга, Татарстан Республикасы медицина оешмасын тоту чыгымнарына түләүгә җибәрә.

13. Медицина оешмалары квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган формалар буенча түбәндәге хисапларны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кертә:

югары технологияле медицина ярдәмен финанслар белән тәэмин итүгә бирелә торган акчадан файдалану турында;

нәтиҗәлелек күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында.

14. Фонд ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 20сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен җибәрелгән Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына кертә.

15. Бюджетара трансфертлардан максатка ярашсыз файдалану бюджет турындагы законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

16. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Фонд хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары торышына карата югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә алынып, файдаланмаган бюджетара трансфертлар хисап елыннан соң килүче елның беренче 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

17. Бу Тәртип нигезендә алынган бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәсә, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемен‌ә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне саклап, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кайтарылырга тиеш.

18. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Фонд бирелгән акчаны медицина оешмаларының өлешчә яки тулысынча кире кайтаруын түбәндәге очракларда тәэмин итә:

әлеге акчага ихтыяҗ булмау (киму);

медицина оешмаларының дөрес булмаган хисаплылык тапшыруы;

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының акчадан максатка ярашсыз файдалануы.

19. Медицина оешмаларына бирелгән акчалар әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән очракларда түбәндәгеләр өлешендә:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләпләрен алган көннән алып 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемен‌ә кире кайтарылырга тиеш;

бюджетара трансфертлар Фондның тиешле таләпләрен алган көннән алып 15 көн эчендә Фонд бюджеты керемен‌ә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан акчаларны кире кайтару срокларын бозган очракта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Фонд әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 30 көн эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә тиешле бюджетка акча түләтү буенча чаралар күрә.

20. Фонд медицина оешмаларыннан килгән акчаны, бу Тәртипнең 18 нче пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча, әлеге акча Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Фондның шәхси счетына күчерелгән көннән соң 3 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтаруны гамәлгә ашыра.

21. Фонд, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе гражданнарына югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы медицина оешмаларына күчерелгән акчадан максатчан файдалануны законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерүдә тотуны тәэмин итәләр.

22. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Килешүдә билгеләнгән формалар буенча түбәндәге хисапларны тапшыра:

аларны финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында;

нәтиҗәлелек күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында.

23. Әлеге Тәртипнең 19 нчы пунктында күрсәтелгән, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы медицина оешмаларына һәм Фондка йөкләнә.